ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
19.12.2022г.

КАРАР
№ 14

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының эшчәнлеге турында
мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында
Кулланучыга аның соравы буенча мәгълүмат

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль законга, прокуратураның 28.11.2022 № 02-01-22-2022 хатына нигезләнеп ,Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 26.03.2013г. №17 (16.02.2015г.№2;04.09.2015г.№14 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының 1 пунктындагы «күрсәтелгән оешмалар» сүзләрен «Башкарма комитет һәм күрсәтелгән оешмалар» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән тулыландырырга:

"4) Башкарма комитет яки аның карамагындагы оешма эшчәнлеге турында мәгълүматны үз эченә алган «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге сайт-рәсми сайт»;

1.3. 2.1 пунктына «шулай ук элемтә челтәрләре буенча гомуми файдалану» сүзләрен өстәргә;

1.4. 2.3 пунктының 1 абзацында «Татарстан Республикасы " сүзләрен «Россия Федерациясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.5 пунктының беренче абзацында «2.10 пункт» сүзләрен «2.11 пункт» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.5 пунктның 2 абзацында «министрлыклар» сүзен «Башкарма комитет» сүзе белән алмаштырырга;

1.7. 2.6 һәм 2.7 пунктларын төшереп калдырырга;

1.8. 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Мәгълүмат мондый информацияне бирү тәртибен регламентлаучы законнар нигезендә түләүсез рәвештә бирелә.»;

1.9. 2.9 пунктының 1 абзацында «2.8 пункт» сүзләрен «2.3 пункт» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 2.9 пунктының 3 абзацын төшереп калдырырга;

1.11. 2.11 пунктның 7 абзацында ", аның территориаль органнарын" төшереп калдырырга;

1.12. 2.11 пунктның 8 абзацында. " «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сүзләрен « рәсми сайт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар аның рәсми басмасыннан соң үз көченә керә һәм 01.12.2022 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы : Р.Х.Салихҗанов